| СОВЕТ КУГЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Күгәй авылы

**2024 елның 9 апреле** **№ 151**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен тапшырырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.
3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру Күгәй авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына ел саен бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталына Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) шулай ук Күгәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнашкан: Күгәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Күгәй авылы, Тынычлык урамы, 20 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Күгәй авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе:** **Ф. Х. Хисаметдинова**